Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино торак пунктында
гражданнар җыены

2026 елда Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино
авыл җирлегенең Иске Гришкино торак пунктында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турында

18.11.2025 ел №4

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгының 2025 елның ноябрендәге 6 нчы номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино авылында гражданнар җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. “2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә билгеләргә. I-II төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарын, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын, 18 яшькә кадәр тәрбиядә балалары булган аз керемле күпбалалы гаиләләрне, көндезге бүлектә укучы студентларны, Россия Армиясе сафларына срок хезмәткә чакырылган гражданнарны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә.

«1) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чабу, агачларны кисү, МТЗ тракторы (Беларус 82) фронталь чүмечле асма төягеч сатып алу);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту, Куйбышев, Ленин, Азин, Елга аръягы урамнарына вак таш салу өчен вак таш сатып алу, зиратка, су башнясына юл салу, транспорт хезмәтләре күрсәтү (автогрейдер хезмәтләре күрсәтү);

3) һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларның исемнәре язылган мемориаль плитәләрне алмаштыру)”?

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Иске Гришкино авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы ____________ К.И.Алексеев
(имза) (имзаны киңәйтү)